| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>ЧУВАШСКО-ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ЧУАШ ЧҮПРӘЛЕСЕ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

с.Чувашское Дрожжаное

18 декабрь 2023 ел №36/2

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Чуаш Чүпрәле авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

«Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 2 ноябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Чуаш Чүпрәле авыл җирлеге советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Чуаш Чүпрәле авыл җирле Советының 2023 елн 20 маендагы 31/1 номерлы (2023 елның 27 июлендәге 32/2 редакциясендә) карары белән расланган Чүпрәле муниципаль районының Чуаш Чүпрәле авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәнең 6 пунктына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1) 11 пунктта** икенче җөмләне төшереп калдырырга**;**

**2) 17 пунктны** үз көчен югалткан дип танырга**;**

**3) 20 пунктны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә**:**

«20. Муниципаль хезмәткәргә класслы чин бирү турындагы карар, әлеге Нигезләмәнең 13 пунктында күрсәтелгән очраклардан тыш, җирле үзидарәнең органына яисә вазыйфаи затына барлык кирәкле документлары булган класслы чин бирү турындагы тәкъдим кертелгән көннән алып бер айдан да соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы сайтында авыл җирлеге бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар, гамәлдәге законнарда каралган очраклардан тыш, рәсми басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Чуаш Чүпрәле авыл җирлеге башлыгы: В.В.Землемеров